РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 49 2024 елның 11 сентябре

**Түбән Кама муниципаль районы Советының 2019 елның 13 февралендәге 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкенә караган, торышы канәгатьләнерлек булмаган россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән файдаланылмый торган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләвен билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 16 маендагы 667 номерлы карары, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 45 статьясы нигезендә Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Советының 2019 елның 13 февралендәге 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкенә караган, торышы канәгатьләнерлек булмаган Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән файдаланылмый торган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләвен билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- мәдәни мирас объектын канәгатьләнерлек хәлдә булмаган (бина, төзелеше яки корылмасы булган) мәдәни мирас объектларына кертү «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 50.1 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән торышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектына кертү критерийлары нигезендә».

2. Әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә торуны Түбән Кама муниципаль районы Советының социаль-икътисадый үсеше, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы башлыгы
вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

А.В. Умников